**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлегенең Сөйки авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**2019 ел, 18 декабре** **№ 1**

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 1 этабы- 2019 нчы елның 16 нчы декабрендә, 2 этабы-2019 нчы елның 17 нче декабрендә, 3 этабы-2019 нчы елның 18 нче декабрендә булып узган халык жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

**- Сөйки авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (шул исәптән кышкы-җәйге чорда) ;**

**- Троицкий чиркәвен ремонтлау;**

**- "Леканов" чишмәсен ремонтлау;**

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 495 кеше кертелгән, 256 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 254 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлегенә керүче Сөйки авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Сөйки авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

**- Сөйки авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (шул исәптән кышкы-җәйге чорда) ;**

**- Троицкий чиркәвен ремонтлау;**

**- "Леканов" чишмәсен ремонтлау;**” мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы,авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз урамы,16а йорты, китапханә бинасы;

шулай ук, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы ,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе В. П. Никитин